**Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Марий Эл Республикасы Хөкүмәте арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, мәдәни һәм башка өлкәләрдә хезмәттәшлек турында**
# КИЛЕШҮ

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Рәисе Миңнеханов Рөстәм Нургали улы йөзендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте, бер яктан, Марий Эл Республикасының «Марий Эл Республикасы Хөкүмәте турында» 2001 елның 18 сентябрендәге 23-З номерлы Законы нигезендә эш итүче Марий Эл Республикасы Хөкүмәте Рәисе Зайцев Юрий Викторович йөзендә Марий Эл Республикасы Хөкүмәте, икенче яктан, алга таба Яклар дип аталып, икътисадый, фәнни-техник, мәдәни һәм башка өлкәләрдә ике яклы бәйләнешләрне саклап калуга һәм киңәйтүгә үзара кызыксынганлыкка таянып, төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту өчен кирәкле тиешле оештыру, икътисадый, хокукый һәм башка шартларны булдырырга теләп, нәтиҗәле хезмәттәшлекне, социаль-икътисадый эшчәнлекләрнең барлык өлкәләрендә тәҗрибә алмашуны һәм даими мәгълүмати хезмәттәшлекне тәэмин итәргә омтылып, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеде.

### 1 статья

Яклар хезмәттәшлекне Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, Марий Эл Республикасы Конституциясе һәм Марий Эл Республикасы законнарына таянып һәм ышаныч, тигез хокуклылык, партнерлык, үзара икътисадый файда, әлеге Килешүнең нигезләмәләрен һәм алар нигезендә ирешелгән килешүләрне үтәү өчен үзара җаваплылык принципларында үстерә.

Яклар әлеге Килешүне үтәү өчен кирәкле мәгълүмат алмаша, Татарстан Республикасы законнарында һәм Марий Эл Республикасы законнарында икенче Якның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылырга һәм (яисә) әлеге Килешүнең үтәлүенә йогынты ясарга мөмкин булган кабул ителгән карарлар һәм үзгәрешләр турында алдан ук язма рәвештә берсе икенчесенә хәбәр бирә, шулай ук икенче Якка икътисадый яисә башка төрле зыян китерердәй гамәлләрдән тыела.

### 2 статья

Яклар фәнни-техник, икътисадый, хокукый һәм башка төр мәгълүмат алмаша, Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы дәүләт

хакимиятләренең башкарма органнары арасында элемтәләрне киңәйтүгә ярдәм итә.

**3 статья**

Яклар үз компетенцияләре чикләрендә түбәндәгеләр өчен шартлар тудыра:

Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы территорияләрендә эшчәнлек алып баручы хуҗалык субъектлары арасында сәүдә-икътисадый элемтәләрне киңәйтү өчен;

Татарстан Республикасының һәм Марий Эл Республикасының кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арасында эшлекле элемтәләр урнаштыру һәм аларны киңәйтү өчен.

Якларның хуҗалык субъектлары үз компетенцияләре чикләрендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм күрсәтү дәүләт программаларын эшләү һәм башкару тәҗрибәсен уртаклаша, Татарстан Республикасында һәм Марий Эл Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү инфраструктурасын оештыру буенча хезмәттәшлеккә, мәгълүмат һәм тәҗрибә алмашуга булышлык итә.

**4 статья**

Яклар төбәкара икътисадый интеграцияне үстерүгә һәм транспорт, мәгълүмат коммуникацияләре, сәнәгать, цифрлы нигездә үсеш, мәгълүмат технологияләре, телекоммуникацияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык, агросәнәгать комплексы, сәүдә һәм хезмәт күрсәтү, архитектура һәм төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр территорияләрен төзекләндерү, сәламәтлек саклау, мәгариф, фән, мәдәният, туристлык һәм спорт, әйләнә-тирә мохитне саклау, гаилә һәм яшьләр сәясәте, социаль юнәлешле дәүләткә карамаган коммерциячел булмаган оешмалар белән хезмәттәшлек, интеллектуаль милек базарын үстерү өлкәләрендә, шулай ук Якларның кызыксыну предметын тәшкил иткән башка өлкәләрдә элемтәләрне ныгытуга ярдәм итә.

**5 статья**

Яклар аларның икесенең дә социаль-икътисадый үсеше өчен өстенлекле әһәмияткә ия булган проектларны үтәүгә ярдәм итә.

Яклар тышкы икътисадый элемтәләрне киңәйтү максатында бер-берсенә ярдәм күрсәтә.

**6 статья**

Яклар инвестиция һәм инновация эшчәнлеге өлкәсендә, шул исәптән түбәндәгеләр буенча, хезмәттәшлек итә:

инвестиция эшчәнлеген үстерү өлкәсендә норматив хокукый актлар турында мәгълүмат алмаша;

бизнес-миссияләр һәм инвестиция мәйданчыкларын һәм инвестиция мөмкинлекләрен тәкъдим итүне оештыра;

рәсми сәфәрләр һәм эшлекле очрашулар кысаларында инвестиция проектларын башкару тәҗрибәсен алмаша;

Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы территорияләрендә инвестиция форумнары, конференцияләре һәм инвестицияләр юнәлешендә башка чаралар уздыру турында мәгълүмат алмаша;

инвестиция проектларын гамәлгә ашыруның иң нәтиҗәле рәвешләрен билгеләп, мәгълүмати-аналитик тәэмин итү системасын үстерә.

**7 статья**

Яклар азык-төлек, сәнәгать товарлары һәм хезмәтләре төбәкара, халыкара күргәзмәләре, ярминкәләре оештыру һәм уздыру тәҗрибәсе алмаша, кызыксыну белдергән хуҗалык субъектларының аларда катнашуына ярдәм итә.

**8 статья**

Яклар фәнгә тирәнтен нигезләнгән производстволар һәм технологияләрне, гамәли әһәмияткә ия булган, шул исәптән сәнәгать җитештерүенә тотыла торган акчаны бүлү, шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре белән бәйле аеруча уңышлы булыр дип фаразланган юнәлешләрне һәм уртак фәнни темаларны эшләү, үзләштерү һәм үстерү өлкәсендә хезмәттәшлек итә.

**9 статья**

Яклар җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре, архитектура, мәдәни мирас объектларын саклау, сәнәгатьтә һәм гражданнарга файдалану өчен билгеләнгән объектларны, торак-коммуналь хуҗалык объектларын урнаштыру һәм төзү, территорияне, Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы территорияләрендә юл хуҗалыгын төзекләндерү өлкәсендә хезмәттәшлек итә, эш тәҗрибәсе турында мәгълүмат алмаша.

## 10 статья

Яклар сәламәтлек саклау өлкәсендә хезмәттәшлек итә, шул исәптән:

Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы медицина оешмалары арасында элемтәләр үстерүгә ярдәм итә;

уртак фәнни гамәли тикшеренүләр уздыру, сәламәтлек саклау хезмәткәрләре делегацияләре алмашу, күчмә семинарлар һәм конференцияләр оештыру мөмкинлеген күз алдында тотып, сәламәтлек саклау теориясе һәм практикасы өлкәсендә казанышлар турында мәгълүмат алмаша;

халыкка дәвалау-профилактика һәм ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүне оештыруны камилләштерү, сәламәтлекне саклау һәм авыруларны кисәтү буенча дәүләт программаларын гамәлгә ашыру буенча эш тәҗрибәсе алмаша;

дарулар, медицина техникасы эшләнмәләре, медицинада файдалану өчен башка продукция базарындагы хәл турында мәгълүмат алмаша.

## 11 статья

Яклар халыкны социаль яклау өлкәсендә хезмәттәшлек итә, шул исәптән:

сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән затларның яшәве өчен уңайлы мохит булдыру һәм үстерү тәҗрибәсен өйрәнә;

халыкны социаль яклау өлкәсендә эш тәҗрибәсен өйрәнү һәм заманча ысуллар һәм технологияләр кертү максатында халыкны социаль яклауга идарә органнары һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре белгечләре делегацияләре алмаша;

халыкны социаль яклау мәсьәләләре буенча мәгълүмат-аналитика материаллары, методик һәм башка материаллар алмаша;

халыкны социаль яклауны оештыру һәм гражданнарның ташламалардан файдаланучы категорияләренә социаль ярдәм күрсәтүнең актуаль мәсьәләләре буенча тәҗрибә алмаша;

Россиянең һәм чит илләрнең хәйрия оешмалары белән элемтәләр урнаштыруга ярдәм итә.

## 12 статья

Яклар мәгариф һәм яшьләр сәясәте өлкәсендә хезмәттәшлек итә, шул исәптән:

яңа мәгълүмати һәм педагогик концепцияләр һәм технологияләрне куллануга кертү буенча эш тәҗрибәсен өйрәнү максатында мәгариф хезмәткәрләре делегацияләре алмаша;

мәгариф хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә;

уртак конференцияләр, семинарлар, сәләтле яшьләрне ачыклау максатында конкурслар һәм олимпиадалар уздыруны оештыра;

яшьләрнең төбәкара яшьләр чараларында катнашуына ярдәм күрсәтә;

яшьләр сәясәте өлкәсендә хезмәттәшлек итә, үз вәкаләтләре кысаларында яшьләрнең гражданнар булып җитешүе, аларга рухи, әхлакый һәм патриотик тәрбия бирү өчен шартлар тудыруга ярдәм итә.

**13 статья**

Яклар мәдәниятнең төрле өлкәләрендә хезмәттәшлекне ныгытуга һәм үстерүгә ярдәм итә, шул исәптән:

мәдәният оешмалары, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре арасында элемтәләрне киңәйтүгә;

театр-концерт коллективлары гастрольләрен оештыруга һәм уздыруга, музей һәм китап күргәзмәләре һәм проектлары алмашуга;

фестивальләр, конкурслар, иҗади очрашулар һәм башка мәдәни чаралар уздыруга;

Татарстан Республикасында һәм Марий Эл Республикасында уздырыла торган милли мәдәни бәйрәмнәрдә, халык сәнгать иҗаты фестивальләре, конкурслары һәм смотрларында һөнәри һәм үзешчән иҗат коллективлары, мәдәният һәм сәнгать әһелләре катнашуга;

мәдәният һәм сәнгать оешмалары эшендә заманча технологияләр куллануга;

халыкларның мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавына алу, аларны саклау, таныту, торгызу мәсьәләләрендә тәҗрибә алмашу һәм төбәк хакимият органнары хезмәттәшлеген үстерү.

**14 статья**

Спорт өлкәсендә Яклар хезмәттәшлек итә, шул исәптән Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы спортчыларының һәм җыелма спорт командаларының Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы территорияләрендә уздырыла торган физкультура, спорт һәм өйрәнү-тренеровка чараларында катнашуына ярдәм итә.

**15 статья**

Туристлык өлкәсендә Яклар хезмәттәшлек итә, шул исәптән:

Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы территорияләрендә булачак чаралар турында мәгълүмат алмаша;

Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы территорияләрендә эшчәнлек алып баручы туристлык оешмалары арасында үзара элемтәләр урнаштыруга ярдәм итә.

**16 статья**

Яклар мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда хезмәттәшлек итә, шул исәптән:

Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы территорияләрендә уздырыла торган күргәзмәләр, конференцияләр һәм башка ачык чараларны оештыруга ярдәм итә;

Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы территорияләрендә мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмалар арасында элемтәләрне киңәйтүгә ярдәм итә;

дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү, ведомствоара электрон хезмәттәшлек, документларның электрон әйләнеше мәсьәләләрендә Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы хакимият органнары эш тәҗрибәсен алмашу һәм хезмәттәшлеген үстерүгә ярдәм итә.

**17 статья**

Яклар түбәндәге юнәлешләр буенча хезмәтне саклау һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәттәшлек итә:

хезмәт ресурсларының хәрәкәтен арттыру, предприятиеләрне, шул исәптән инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы кадрлар белән тәэмин итү өлкәсендә мәгълүмат һәм эш тәҗрибәсе алмаша;

төрле төбәкләр арасында һәм бер төбәктә биләнмәгән эш урыннары ярминкәләре оештыру һәм уздыру буенча тәҗрибә алмашу, шулай ук Якларның вәкилләренә әлеге чараларда катнашулары барышында оештыру ярдәме күрсәтү;

хезмәтне саклау һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә яңа технологияләр кертү турында мәгълүмат һәм тәҗрибә алмашу.

Яклар хезмәтне саклау һәм һөнәри авыруларны кисәтү өлкәсендә мәгълүмати-аналитик материаллар алмашу юлы белән хезмәттәшлек итә.

**18 статья**

Яклар милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә, шул исәптән милли-мәдәни мохтариятләр, дини оешмалар һәм башка иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итү буенча мәгълүмат һәм тәҗрибә алмаша.

**19 статья**

Яклар табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә түбәндәге юнәлешләр буенча хезмәттәшлек итә:

кыен хәл тудыра торган экологик мәсьәләләр, әйләнә-тирә мохитне саклауны фәнни-методик тәэмин итү буенча тәҗрибә алмашу;

табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүгә идарә системасын камилләштерү өлкәсендә тәҗрибә (җитештерү һәм куллану калдыкларын җыю, транспортта ташу, эшкәртү һәм зарарсызландыру системасын оештыру, каты коммуналь калдыкларны күмү полигоннарындагы җир катлавын тернәкләндерү тәҗрибәсе) һәм мәгълүмат алмашу;

Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының ау һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә Россия Федерациясенең үзләренә тапшырылган вәкаләтләрен башкару буенча мәгълүмат һәм тәҗрибә алмашу;

җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре, Татарстан Республикасы Кызыл китабын һәм Марий Эл Республикасы Кызыл китабын алып бару, төбәк күләмендә әһәмияткә ия булган, аеруча саклана торган табигать территорияләрендә экологик туристлыкны үстерү, төбәк күләмендә әһәмияткә ия булган, аеруча саклана торган табигать территорияләрен оештыру һәм аларның эшләве өлкәсендә хезмәттәшлек итү һәм тәҗрибә алмашу.

**20 статья**

Яклар юл-транспорт инфраструктурасы өлкәсендә хезмәттәшлек итә, шул исәптән әлеге өлкәдә тәҗрибә һәм мәгълүмат алмаша.

**21 статья**

Яклар түбәндәгеләрне башкара:

архив эше өлкәсендә норматив хокукый актлар, норматив-методик документлар, фәнни-тикшеренү эше нәтиҗәләре, архив документларын бастырып чыгару, архивларны өйрәнү, археография һәм документлар өйрәнү өлкәсендә әдәбият буенча мәгълүмат, уртак кызыксыну тудырган башка мәгълүмат алмашу;

Якларның архив эше тәҗрибәсен өйрәнү һәм әлеге тәҗрибәне алмашу;

үзара килешеп – бер Якның архив учреждениеләре хезмәткәрләренең икенче Якның архив учреждениеләренә архив эше өлкәсендәге алдынгы тәҗрибәне уртаклашу өчен эш сәфәрләре;

Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы халыклары тарихы буенча документлар күчермәләрен алмашу;

уртак фәнни һәм фәнни-гамәли чаралар (конференцияләр, түгәрәк өстәлләр, семинарлар, тарихи-документаль күргәзмәләр һ.б.) һәм архив

документларын җәмәгатьчелеккә таныту һәм аларны файдалану өлкәсендә чаралар һәм белгечләрне стажировкалауны уздыру.

**22 статья**

Яклар дәүләт тарафыннан законнар нигезендә товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, өстәмә бәяләрне һ.б.) җайга салу өлкәсендә, шулай ук тарифларны җайга салу органының гражданнарның коммуналь хезмәтләр өчен түләве үзгәрүенең чик (иң югары) индексларын раслау һәм аларның үтәлүен мониторинглау мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары белән бергәләп эшләве өлкәсендә хезмәттәшлек итә һәм эш тәҗрибәсе алмаша.

**23 статья**

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә Яклар үз вәкаләтләре чикләрендә законнар нигезендә үсемлекчелек, селекция, орлыкчылык буенча, үсемлекләрне саклауның алдынгы технологияләрен һәм чараларын бергәләп файдалану өчен тиешле оештыру шартлары булдыру юлы белән агросәнәгать комплексы оешмаларына ярдәм итә.

**24 статья**

Яклар дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен, шулай ук сатып-алу эшләре «Аерым юридик затлар тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына торган юридик затлар ихтыяҗлары өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә тәҗрибә һәм мәгълүмат алмаша.

**25 статья**

Әлеге Килешү аңа кул куйган Якларга финанс һәм (яки) мөлкәт йөкләмәләре салмый.

Әлеге Килешүне үтәү буенча Россия Федерациясе бюджет законнарына, Татарстан Республикасы бюджет законнарына һәм Марий Эл Республикасы бюджет законнарына нигезләнеп башкарылырга тиешле чаралар Татарстан Республикасы бюджетында һәм Марий Эл Республикасы бюджетында тиешле финанс елына һәм план чорына карала торган бюджет ассигнованиеләре хисабыннан билгеләнгән тәртиптә финанслана.

Яклар яшерен буларак яисә Яклар яшерен дип санарга килешкән мәгълүмат буларак тапшырылган мәгълүматның яшеренлеген тәэмин итүне үз өстенә йөкли.

Әлеге Килешүне үтәү белән бәйле эш алып барганда, Яклар «Конкурентлыкны саклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәшү турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм коррупциягә каршы көрәшү өлкәсендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасының һәм Марий Эл Республикасының башка норматив хокукый актлары таләпләрен үтәүне һәм Якларның вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлүе буенча чаралар күрүне үз өстенә йөкли.

## 26 статья

Яклар әлеге Килешүдә билгеләнгән хезмәттәшлек юнәлешләре буенча уртак күргәзмәләр, конференцияләр, семинарлар, киңәшмәләр, түгәрәк өстәлләр, презентацияләр һәм башка чараларны уздыруны оештыра.

Әлеге Килешү Яклар тарафыннан хезмәттәшлекнең тәгаен өлкәләрендә килешүләр төзү һәм беркетмәләр (чаралар планнары) раслау өчен нигез булып тора. Якларның өченче яклар белән төзелгән килешүләре һәм расланган беркетмәләр (чаралар планнары) буенча йөкләмәләренә ул кагылмый һәм шуңа күрә аларның кайсысының да булса мәнфәгатьләренә зыян китерердәй итеп файдаланыла яисә өченче яклар алдында алынган йөкләмәләрен үтәүгә киртә була алмый.

## 27 статья

Әлеге Килешүне гамәлгә ашыру буенча бәхәсле мәсьәләләр килеп чыккан очракта, алар Яклар арасында консультацияләр һәм сөйләшүләр уздыру юлы белән хәл ителергә тиеш.

## 28 статья

Әлеге Килешү аңа кул куйган көннән үз көченә керә һәм биш ел дәвамында гамәлдә була. Әгәр Якларның берсе үзенең әлеге Килешүне өзәргә теләве хакында аның гамәле вакыты тәмамланганга кадәр икенче Якка язма рәвештә хәбәр бирмәсә, әлеге Килешү бер елга үзеннән-үзе озайтыла.

Әлеге Килешү ул гамәлдә булган чорда Якларның язма рәвештә белдерелгән үзара килешүе буенча теләсә кайсы вакытта өзелә ала.

Бер Як икенче Якка язма рәвештә хәбәр биргәннән соң 30 көн эчендә әлеге Килешү берьяклы тәртиптә өзелә ала.

Яклар үзара килешеп әлеге Килешүне үзгәртә ала. Әлеге Килешүгә кертелгән барлык үзгәрешләр, язма рәвештә башкарылган һәм Якларның вәкаләтле затлары тарафыннан кул куелган булсалар, гамәлдә була.

Әлеге Килешү 2024 елның «12» февралендә Казан шәһәрендә рус һәм татар телләрендә бер үк төрле көчкә ия ике нөсхәдә, Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә башкарылды.

| **Татарстан Республикасы Хөкүмәте** | **Марий Эл Республикасы Хөкүмәте** |
| --- | --- |
| Татарстан Республикасы Рәисе | Марий Эл Республикасы Хөкүмәте Рәисе |
| ____________ Р.Н. Миңнеханов | ____________ Ю.В. Зайцев |

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ • ГЛАВА (РАИС) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

14.02.2024
№ 2